**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об установлении ограничительных мероприятий (карантина) на отдельных территориях Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию высокопатогенным гриппом птиц и угрозой его распространения

В связи с выявлением заболевания высокопатогенным гриппом птиц и угрозой его распространения на отдельных территориях Республики Татарстан, в соответствии со статьей $3^1$, 17 Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии», приказом Министерства сельского хозяйства Российской Федерации от 27 марта 2006 года № 90 **постановляю**:

1. Установить ограничительные мероприятия (карантин) по высокопатогенному гриппу птиц на период до их отмены на следующих отдельных территориях Республики Татарстан:

частные подворья домов № 45, 86 по улице Нижне-Нурлатская в городе Нурлате;

часть территории фермы, используемой крестьянским (фермерским) хозяйством «Хамидуллин З.З.» для содержания домашней птицы, в городе Нурлате;

часть территории фермы, используемой крестьянским (фермерским) хозяйством «Хамидуллин З.З.» для содержания домашней птицы, у деревни Чувашская Менча Нурлатского района;

частное подворье дома № 18 по улице Центральная в селе Шумково Рыбно-Слободского района;

частное подворье дома № 1 по улице Луговая в селе Абсалямово Ютазинского района;

частное подворье дома № 90 по улице 3-я Кленовая в жилом массиве Дербышки города Казани.

2. Утвердить прилагаемый Перечень ограничений на оборот птицы, продуктов птицеводства, кормов и кормовых добавок на отдельных территориях Республики Татарстан, определенных пунктом 1 настоящего Указа, на период до их отмены.

3. Определить:

а) эпизоотические очаги в пределах следующих отдельных территорий Республики Татарстан (далее – неблагополучные пункты):

частные подворья домов № 45, 86 по улице Нижне-Нурлатская в городе Нурлате;

часть территории фермы, используемой крестьянским (фермерским) хозяйством «Хамидуллин З.З.» для содержания домашней птицы, в городе Нурлате;

часть территории фермы, используемой крестьянским (фермерским) хозяйством «Хамидуллин З.З.» для содержания домашней птицы, у деревни Чувашская Менча Нурлатского района;

частное подворье дома № 18 по улице Центральная в селе Шумково Рыбно-Слободского района;

частное подворье дома № 1 по улице Луговая в селе Абсалямово Ютазинского района;

частное подворье дома № 90 по улице 3-я Кленовая в жилом массиве Дербышки города Казани;

б) угрожаемые зоны в пределах территорий радиусом 5 км от границ неблагополучных пунктов, включая следующие отдельные территории Республики Татарстан:

деревня Чувашская Менча, поселок Чишма Нурлатского района, город Нурлат;

село Шумково, деревня Хутор, деревня Большой Атмас, село Балыклы-Чукаево, деревня Новый Салтан, деревня Ошняк-Качкалак Рыбно-Слободского района;

село Абсалямово, село Старые Уруссу, поселок железнодорожного разъезда Абсалямово, поселок городского типа Уруссу Ютазинского района;

жилой массив Дербышки, жилой массив Нагорный, жилой массив Большие Дербышки, жилой массив Кульсеитово города Казани, поселок Березовка Высокогорского района;

в) зоны наблюдения в пределах территорий радиусом 10 км от границ неблагополучных пунктов, включая следующие отдельные территории Республики Татарстан:

деревня Светлое Озеро, село Новое Иглайкино, деревня Старое Иглайкино, поселок Тукай, поселок Некрасовка, село Средняя Камышла, деревня Малая Камышла, деревня Вишневая Поляна, деревня Абляскино, поселок Красный Октябрь, поселок Михайловка, деревня Караульная Гора, деревня Русская Менча, село Якушкино, село Аксумла, деревня Ахметово, деревня Ерепкино, село Егоркино, поселок Березовка, деревня Осиновка Нурлатского района;

поселок Губайдулловка, деревня Дикое Поле, село Старый Арыш, деревня Малый Атмас Рыбно-Слободского района;

деревня Яссы-Тугай, деревня Тарлау, деревня Ак-Юл, деревня Алабакуль, деревня Каклы-Куль, село Ютаза, деревня Таш-Кичу, деревня Малые Уруссу, село Байларово, село Дым-Тамак Ютазинского района;

Авиастроительный, Ново-Савиновский, Советский (за исключением жилых массивов, указанных в абзаце пятом подпункта «б» настоящего пункта) районы города Казани, деревня Макаровка, поселок Дачное, село Высокая Гора, поселок Инеш, село Пановка, село Пермяки, деревня Эстачи Высокогорского района.

4. Главному управлению ветеринарии Кабинета Министров Республики Татарстан разработать и утвердить план мероприятий по ликвидации очага высокопатогенного гриппа птиц и предотвращению распространения возбудителя болезни на территории Республики Татарстан.

5. Контроль за исполнением настоящего Указа возложить на Кабинет Министров Республики Татарстан.

6. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань,Кремль
16 мая 2017 года
№ УП-394

Приложение
к Указу Президента
Республики Татарстан

от « 16» мая 2017 года

№ УП - 394

ПЕРЕЧЕНЬ
ограничений на оборот птицы, продуктов птицеводства, кормов и кормовых добавок на отдельных территориях Республики Татарстан на период до их отмены

На период действия ограничительных мероприятий (карантина) на территориях неблагополучных пунктов:

закрыть доступ на территорию посторонним лицам и транспорту;

прекратить посещение посторонними лицами, кроме персонала, непосредственно их обслуживающего, и дополнительно закрепленных на период проведения мероприятий работников и специалистов в области ветеринарии;

ограничить передвижение персонала, обслуживающего неблагополучную группу птиц, по территории, исключить его контакт с другими птицами и ухаживающими за ними лицами;

организовать бескровный убой больной птицы, сбор павшей и убитой птицы в герметичную тару;

провести при массовом бескровном убое больной птицы ее захоронение в установленном порядке в условиях, исключающих рассеивание предполагаемого возбудителя болезни во внешней среде;

прекратить перемещение птицы внутри эпизоотического очага и вывоз из него птицы, яиц и других продуктов птицеводства, а также вывоз кормов, инвентаря, оборудования, помета;

прекратить посещение других домовладений, где имеется домашняя птица, вывоз живой птицы и полученной от нее продукции, вынос (вывоз) инвентаря, оборудования, помета;

прекратить выгул или иное использование птицы за границами эпизоотического очага;

приостановить торговлю птицей;

закрыть все дороги (тропы), ведущие из неблагополучного пункта, выставить необходимое количество круглосуточных контрольно-пропускных постов, оборудованных дезбарьерами, пароформалиновыми камерами для обработки одежды и дезинфекционными установками, с круглосуточным дежурством, с привлечением ветеринарных инспекторов и сотрудников правоохранительных органов;

ограничить передвижение транспорта в зоне карантина, при этом допущенный транспорт подлежит обязательной дезинфекции на въезде и выезде из карантинной зоны;

провести мероприятия по убою и уничтожению восприимчивого поголовья.

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү һәм аның таралу куркынычы янау белән бәйле рәвештә, аның иминлексезлеге сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында

Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә кошларның йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү очрагы ачыклану һәм аның таралу куркынычы янау белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2006 елның 27 мартындагы 90 номерлы карары нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы буенча, аларны бетерү турында карар кабул ителгәнгә кадәр, чикләү чараларын (карантин) кертергә:

Нурлат шәһәренең Түбән Нурлат урамындагы 45, 86 номерлы йортларның шәхси хуҗалыклары;

Нурлат шәһәрендә «Хәмидуллин З.З.» крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан кош-корт асрау өчен кулланыла торган ферма территориясенең бер өлеше;

«Хәмидуллин З.З.» крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан кош-корт асрау өчен кулланыла торган ферма территориясенең Нурлат районы Чуаш Мәнҗесе авылы янындагы бер өлеше;

Балык Бистәсе районының Шумково авылының Үзәк урамындагы 18 номерлы йортның шәхси хуҗалыгы;

Ютазы районы Әбсәләм авылының Луговая урамындагы 1 номерлы йортның шәхси хуҗалыгы;

Казан шәһәре Дербышки торак массивының 3 нче Кленовая урамындагы 90 номерлы йортның шәхси хуҗалыгы.

2. Татарстан Республикасының әлеге Указның 1 пункты нигезендә билгеләнгән аерым территорияләрендә кош, кошчылык продуктларын, азык һәм азыкка өстәмәләрнең әйләнешенә чикләүләр исемлеген, аларны бетерү турында карар кабул ителгәнгә кадәр, расларга.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләре чикләрендә (алга таба – имин булмаган пунктлар) эпизоотия чыганакларын:

Нурлат шәһәренең Түбән Нурлат урамындагы 45, 86 номерлы йортларның шәхси хуҗалыклары;

Нурлат шәһәрендә «Хәмидуллин З.З.» крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан кош-корт асрау өчен кулланыла торган ферма территориясенең бер өлеше;

«Хәмидуллин З.З.» крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан кош-корт асрау өчен кулланыла торган ферма территориясенең Нурлат районы Чуаш Мәнҗесе авылы янындагы бер өлеше;

Балык Бистәсе районының Шумково авылының Үзәк урамындагы 18 номерлы йортның шәхси хуҗалыгы;

Ютазы районы Әбсәләм авылының Луговая урамындагы 1 номерлы йортның шәхси хуҗалыгы;

Казан шәһәре Дербышки торак массивының 3 нче Кленовая урамындагы 90 номерлы йортның шәхси хуҗалыгы;

б) имин булмаган пункт чикләреннән 5 км радиустагы территория чикләрендә, шул исәптән Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрен дә кертеп, куркыныч янау зоналарын:

Нурлат районының Чуаш Мәнҗесе, Чишмә поселогы, Нурлат шәһәре;

Балык Бистәсе районының Шумково авылы, Хутор авылы, Олы Укмас авылы, Балыклы Чүкәй авылы, Яңа Солтан авылы, Әшнәк-Качкалак авылы;

Ютазы районының Әбсәләм авылы, Иске Урыссу авылы, Әбсәләм тимер юл разъезды поселогы, Урыссу шәһәр тибындагы поселогы;

Казан шәһәре Дербышки торак массивы, Нагорный торак массивы, Олы Дербышки торак массивы, Колсәет торак массивы, Биектау районының Березовка поселогы;

в) имин булмаган пунктлар чикләреннән 10 км радиустагы территорияләр чикләрендә, шул исәптән Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрен дә кертеп, күзәтү зоналарын:

Нурлат районының Яктыкүл авылы, Яңа Иглай авылы, Иске Иглай авылы, Тукай поселогы, Некрасовка поселогы, Урта Камышлы авылы, Кече Камышлы авылы, Чияле Алан авылы, Абляскино авылы, Кызыл Октябрь поселогы, Михайловка поселогы, Каравыл Тавы авылы, Рус Мәнҗесе авылы, Якушкино авылы, Аксумла авылы, Әхмәт авылы, Ярәп авылы, Егоркино авылы, Березовка поселогы, Осиновка авылы;

Балык Бистәсе районының Гобәй поселогы, Дикое Поле авылы, Иске Арыш авылы, Кече Укмас авылы;

Ютазы районының Яссытугай авылы, Тарлау авылы, Акъюл авылы, Алабакүл авылы, Какылы Күл авылы, Ютазы авылы, Ташкичү авылы, Кече Урыссу авылы, Байлар авылы, Димтамак авылы;

Казан шәһәренең Авиатөзелеш, Яңа Савиново, Совет районнары (әлеге пунктның «б» пунктчасындагы бишенче абзацта күрсәтелгән торак

массивларыннан тыш), Биектау районы Макаровка авылы, Дачный поселогы, Биектау авылы, Инеш поселогы, Пановка авылы, Пермяк авылы, Эстачи авылы.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә йогышлылыгы югары булган кош гриппы чыганагын бетерү һәм авыру чыганагының Татарстан Республикасы территориясендә таралуын булдырмау буенча чаралар планын эшләргә һәм расларга.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2017 ел, 16 май
№ ПУ-394

Татарстан Республикасы
Президентының
2017 елның « 16 » маендагы
ПУ- 394 номерлы Указына
кушымта

Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә, аларны бетерү турында карар кабул ителгәнче, кош, кошчылык продуктлары, азык һәм азыкка өстәмәләр әйләнешенә чикләүләр
ИСЕМЛЕГЕ

Чикләү чаралары (карантин) гамәле вакытында имин булмаган пунктлар территорияләрендә:

территориягә чит кешеләр керүне һәм транспорт керүне туктатырга;

турыдан-туры хезмәт күрсәтүче персоналдан һәм чаралар уздырыла торган вакытка өстәмә рәвештә беркетелгән ветеринария өлкәсендәге хезмәткәрләр һәм белгечләрдән тыш чит кешеләр керүне тыярга;

кошларның иминлексез төркеменә хезмәт күрсәтүче персоналның территория буйлап йөрүен чикләргә, аларның башка кошлар һәм аларга хезмәт күрсәтүче затлар белән аралашуын булдырмаска;

чир йоктырган кошларны кан чыгармыйча юк итүне, үлгән һәм юк ителгән кошларны герметик тарага җыюны оештырырга;

кан чыгармыйча массачыл төстә кошларны юк итү вакытында, авыру тудыручы дип күздә тотылган чыганакның әйләнә-тирә мохиттә таралуын булдырмау шартларында, үләксәләрне күмүне билгеләнгән тәртиптә уздырырга;

эпизоотия чыганагы эчендә кошларны күчерүне һәм аннан кошларны, йомыркаларны һәм башка кошчылык продуктларын, шулай ук кош азыгы, эш коралларын, җиһазларны, кош тизәген чыгаруны туктатырга;

кош-корт асрый торган башка йорт биләмәләренә керүне тыярга, кошларны һәм аннан алынган продуктларны, эш коралларын, җиһазларны, кош тизәген чыгаруны туктатырга;

эпизоотия чыганагы чикләреннән кошларны чыгаруны һәм аларны башкача файдалануны туктатырга;

кошлар сатуны вакытлыча туктатырга;

имин булмаган пунктка илтүче барлык юлларны (сукмакларны) ябарга, кирәкле санда дезинфекцияләү киртәләре, кием-салымны эшкәртү өчен пароформалин камералары һәм дезинфекцияләү җайланмалары белән җиһазландырылган тәүлек әйләнәсе кизү торачак контроль-үткәрү постлары куярга, аларда эшләргә ветеринария инспекторларын һәм хокук саклау органнары хезмәткәрләрен җәлеп итәргә;

карантин зонасында транспорт хәрәкәтен чикләргә, шул исәптән керү рөхсәт ителгән транспорт карантин зонасына кергәндә һәм аннан чыкканда мәҗбүри дезинфекциялөнергә тиеш;

авыруларга аеруча бирешүчән баш санын сую һәм юкка чыгару буенча чаралар уздырырга.